КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 декабрь г.Казань № 1100

2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 5 декабрь, 1100 нче карары белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларга (алга таба - коммерциягә карамаган оешмалар) эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында коммуналь хезмәтләр өчен түләү һәм биналарга эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен түләү өлешендә субсидияләр бирү (алга таба - субсидия) механизмын билгели.

2. Субсидияләр «2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнар;

бүлмәләргә эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү өчен түләү чыгымнары.

5. Субсидия бирү (алга таба - сайлап алу) өчен коммерцияле булмаган оешманы сайлау коммерцияле булмаган оешманың сайлап алу критерийларына һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (гаризалар) килү чиратлылыгына туры килүеннән чыгып, тәкъдимнәрне (алга таба - гариза) соратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Сайлап алу критерийлары:

коммерцияле булмаган оешма үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

коммерциягә карамаган оешма дәүләт милкеннән түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан бирелгән

бүлмәләрне биләп тора һәм коммуналь хезмәтләр һәм бүлмәләргә эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр өчен түли;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру коммерциягә карамаган оешманың устав эшчәнлеге юнәлеше булып тора.

7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

8. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт), гаризалар кабул итәлә башлау көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп урнаштырыла:

сайлап алуны үткәрү срокларын, гаризалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

әлеге Тәртипнең 21 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итәлә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга карата таләпләрне һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

коммерциягә карамаган оешманы сайлау критерийларын;

гаризалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

гаризаларны кире алу тәртибен, гаризаларны кире кайтару (шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, гаризага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 13 – 17 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

гаризаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

гаризаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүматны;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.

9. Коммерциягә карамаган оешмага, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килсә, сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителә:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган БМО VII Уставы башлыгы, БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә түгел;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка орматив хокукый актлары нигезендә акча алмау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмау;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан

Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (мәгариф оешмасына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, мәгариф оешмасына карата банкротлык процедурасы билгеләнмәсә, мәгариф оешмасының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау.

10. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада гариза кертә, аңа түбәндәгеләр кирә:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерцияле булмаган оешма турында, аның тарафыннан бирелгән гариза, сайлау үткәрүгә бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып);

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар сметасы;

коммерциягә карамаган оешманың бердәй салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары юклыгы йә бурыч Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмау турында белешмә;

коммерциягә карамаган оешма һәм дәүләт бюджет учреждениесе арасында төзелгән дәүләт мөлкәтеннән түләүсез файдалану шартнамәсенең күчермәсен;

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган гарантияле хат.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу пунктның бишенче абзацында каралган документ тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.P117

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар бер папкага (том) тутырылырга, битләренә номерлар сугылырга, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең үз кулы белән имзаланырга һәм мөһер белән таныкланырга тиеш (мөһер булганда).

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (коммерцияле булмаган оешма җитәкчесенең үз имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

11. Бер коммерциягә карамаган оешма бер генә гариза бирергә мөмкин.

12. Министрлык гаризаны кергән көнне кабул итә һәм терки.

13. Министрлык гаризаларны карау максатларында 6 кешедән торган гаризаларны карау буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзи. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлык хезмәткәрләре арасыннан Комиссия рәисе һәм әгъзалары керә.

Комиссия эше аның утырышларында башкарыла. Әгәр утырышта Комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.

Гаризалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Комиссия коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тәкъдим ителгән гаризаның һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның керү чираты нигезендә карап тикшерелә, шулай ук коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүен билгели.

Гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны карап тикшерү йомгаклары турында Комиссия карарлары Комиссиядә катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

Гаризаларны карау нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары кулын куя һәм Комиссия утырышы үткәрелгән көнне Министрлыкка тапшырыла.

14. Гаризаларны карап тикшерү стадиясендә гаризаны кабул итмәү өчен нигезләр:

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган гаризаның һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә гаризаларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслау максатларында коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

гаризалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң гариза бирү;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

15. Министрлык беркетмә нигезендә сайлап алу җиңүчесен билгели һәм беркетмәгә имза салганнан соң 10 көн эчендә субсидия алучыга субсидияләр бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Министрлык карары боерык белән рәсмиләштерелә.

16. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы); P111

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

17. Сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган унынчы календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм рәсми сайтта урнаштырыла, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

гаризаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

гаризалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый гаризалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

18. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P_1 + P_2,$$

монда:

$P_1$ – коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнар;

$P_2$ - бүлмәләргә эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү хезмәтләре өчен түләү чыгымнары.

Бу пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар Россия Федерациясе законнары нигезендә, шулай ук бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.

19. Субсидия бирү Министрлык һәм субсидия алучы арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында,

шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Министрлык тарафыннан аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә;

субсидия алучының, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ и $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр.

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

20. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

21. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсеше, аларның этномәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту өлкәсендә гамәлгә ашырылган чаралар саны - кимендә бер чара;

катнашучылар саны – кимендә 100 кеше.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы - 2024 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча. Әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән карар Министрлык тарафыннан кабул ителгән очракта, килешүдә билгеләнә торган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы 2025 елның 31 декабреннән дә соңга калып билгеләнә алмый.

22. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына бер тапкыр күчерелә.

23. Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

24. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

25. Субсидия алучы Министрлыкка квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 5 көненнән дә соңга калмыйча, Килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирә.

Министрлык килгән хисапларны Министрлыкка кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки һәм аларны тикшерүне теркәү датасыннан башлап эш көннәрендә исәпләнән торган 10 көн эчендә башкара.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.

26. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше булганда, субсидия алучы Министрлыкка 2025 елның 15 гыйнварына кадәр күрсәтелгән чараларга ихтыяҗны нигезли торган документлар тапшыра.

Министрлык субсидия алучыдан әлеге документларны алган көннән соң 15 көн эчендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидия алучының әлеге акчага ихтыяҗы булу турында яки аларга ихтыяҗ булмаганда әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтару хакында карар кабул итә.

27. Субсидия алучының хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында Министрлык карары булмаган очракта, субсидия алучы әлеге акчаны 2025 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарырга тиеш.

28. Министрлык тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә субсидия алучының ихтыяҗы булу турында Министрлык карары булган очракта, субсидия алучы финанс белән тәэмин итү

чыганагы булып әлеге акча торган чыгымнарны бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотарга хокуклы.

29. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

30. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы һәм (яисә) субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар тарафыннан субсидияләр бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар, максатлар һәм тәртип бозылган очракта;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән очракта, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән һәр күрсәткече өчен биш процент күләмендә;

31. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 27 һәм 30 пунктларында билгеләнгән субсидияне иректе кире кайтару срогы бозылган очракта, Министрлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

32. Субсидияне файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.